КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 декабрь г.Казань № 1121

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 24 март, 146 нчы карары белән расланган Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт Герое, Россия Федерациясе Хезмәт Герое исемнәре бирелгән, Дан орденының тулы кавалерлары булган, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнгән гражданнарга «Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы турында» 1993 елның 15 гыйнварындагы 4301-1 номерлы Россия Федерациясе законында, «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль гарантияләр бирү турында» 1997 елның 9 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ташламалар бирүгә бәйле чыгымнарны финанслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт Герое, Россия Федерациясе Хезмәт Герое исемнәре бирелгән, Дан орденының тулы кавалерлары булган, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнгән гражданнарга «Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы турында» 1993 елның 15 гыйнварындагы 4301-1 номерлы Россия Федерациясе

законында, «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль гарантияләр бирү турында» 1997 елның 9 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ташламалар бирүгә бәйле чыгымнарны финанслау тәртибен раслау турында» 2005 ел, 24 март, 146 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 13 июнь, 301 нче; 2007 ел, 29 апрель, 167 нче; 2007 ел, 16 май, 188 нче; 2007 ел, 6 декабрь, 697 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 634 нче; 2023 ел, 3 апрель, 391 нче; 2023 ел, 19 сентябрь, 1162 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое, Социалистик Хезмәт Герое, Россия Федерациясе Хезмәт Герое исемнәре бирелгән, Дан орденының тулы кавалерлары булган, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнгән гражданнарга «Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы турында» 1993 елның 15 гыйнварындагы 4301-1 номерлы Россия Федерациясе законында, «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль гарантияләр бирү турында» 1997 елның 9 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ташламалар бирүгә бәйле чыгымнарны финанслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына яки Дан орденының тулы кавалерларына шифаханә-курорт юлламалары кыйммәте өчен түләү, торак урыннан файдаланган (наем) өчен түләү, торак урынны карап тоткан өчен түләү, коммуналь хезмәтләр өчен түләү, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен түләү, өй телефонын урнаштыру өчен түләү, ведомстводан тыш саклау сигнализациясе чараларыннан файдаланган һәм торак бүлмәләрен алар белән җиһазландырган өчен түләү, Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына торак бүлмәләрендә ведомстводан тыш саклау сигнализациясеннән файдаланган өчен түләү, Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына яисә Дан орденының тулы кавалерларына автомобиль ягулыгы чыгымнары өчен компенсация түләү, аэропорт һәм аэровокзалларның, тимер юл вокзалларының һәм станцияләренең, диңгез вокзалларының (портларның) һәм елга вокзалларының рәсми затлары һәм делегацияләр өчен залларыннан файдаланган өчен түләү, Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое яки Дан орденының тулы кавалеры вафат булган (һәлак булган) очракта, күмү, кабер ташын ясау һәм кую чыгымнарына түләү, 20 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләү, «Татарстан геройлары» иҗтимагый оешмасының бүлмәне арендалауга һәм телефоннан файдалануга бәйле чыгымнар өчен компенсация түләү өлешендә;»;

5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына яки Дан орденының тулы кавалерларына шифаханә-курорт юлламалары кыйммәте өчен

түләүгә, торак урыннан файдаланган (наем) өчен түләүгә, торак урынны карап тоткан өчен түләүгә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә, күпфатирлы йорттагы уртак милеккә капиталь ремонт ясау өчен түләүгә, өй телефонын урнаштыру өчен түләүгә, ведомстводан тыш саклау сигнализациясе чараларыннан файдаланган һәм торак бүлмәләрен алар белән җиһазландырган өчен түләүгә, Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына торак бүлмәләрендә ведомстводан тыш саклау сигнализациясеннән файдаланган өчен түләүгә, Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына яисә Дан орденының тулы кавалерларына автомобиль ягулыгы чыгымнары өчен компенсация түләүгә, аэропорт һәм аэровокзалларның, тимер юл вокзалларының һәм станцияләренең, диңгез вокзалларының (портларның) һәм елга вокзалларының рәсми затлары һәм делегацияләр өчен залларыннан файдаланган өчен түләүгә, Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое яки Дан орденының тулы кавалеры вафат булган (һәлак булган) очракта, күмү, кабер ташын ясау һәм кую чыгымнарына түләүгә, 20 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләүгә, «Татарстан геройлары» иҗтимагый оешмасының бүлмәне арендалауга һәм телефоннан файдалануга бәйле чыгымнар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслауга заявкалар буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә акча күчерүне гамәлгә ашыра;»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе:

«Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына яки Дан орденының тулы кавалерларына шифаханә-курорт юлламалары сатып алуга, торак урыннан файдаланган (наем) өчен түләүгә, торак урынны карап тоткан өчен түләүгә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә, күпфатирлы йорттагы уртак милеккә капиталь ремонт ясау өчен түләүгә, өй телефонын урнаштыру өчен түләүгә, ведомстводан тыш саклау сигнализациясе чараларыннан файдаланган һәм торак бүлмәләрен алар белән җиһазландырган өчен түләүгә, Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына торак бүлмәләрендә ведомстводан тыш саклау сигнализациясеннән файдаланган өчен түләүгә, Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына яисә Дан орденының тулы кавалерларына автомобиль ягулыгы чыгымнары өчен компенсация түләүгә, аэропорт һәм аэровокзалларның, тимер юл вокзалларының һәм станцияләренең, диңгез вокзалларының (портларның) һәм елга вокзалларының рәсми затлары һәм делегацияләр өчен залларыннан файдаланган өчен түләүгә, Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое яки Дан орденының тулы кавалеры вафат булган (һәлак булган) очракта, күмү, кабер ташын ясау һәм кую чыгымнарына түләүгә, 20 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләүгә, «Татарстан геройлары» иҗтимагый оешмасының бүлмәне арендалауга һәм телефоннан файдалануга бәйле чыгымнар өчен компенсация түләүгә бәйле чыгымнарны финанслауга заявкалар формалаштыра;

акча алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә һәм торак урыннан файдаланган (наем), торак урынны карап тоткан һәм коммуналь хезмәтләр өчен

түләү, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен кертем буенча бирелгән ташламалар турындагы хисаплар нигезендә акчаны идарәче компанияләргә (барлык милек рәвешләрендәге торак фонды идарәсендә булган оешмаларга), район җитештерү участокларына, эксплуатация җитештерү идарәләренә, турыдан-туры шартнамәләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче башка оешмаларга күчерә;

гражданнарга яисә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләргә – күмү, махсуслаштырылган предприятиеләргә – кабер ташын ясау һәм кую чыгымнарын гамәлгә ашыру өчен акча түләүне (күчерүне) башкара;

Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое яки Дан орденының тулы кавалеры вафат булган (һәлак булган) очракта, гражданнарга 20 000,0 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган пособие түләүне (күчерүне) башкара;

Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына һәм Дан орденының тулы кавалерларына автомобиль ягулыгы чыгымнарын компенсацияләү өчен акча түләүне (күчерүне) башкара;

төзелгән шартнамәләр нигезендә предприятиеләргә һәм оешмаларга өй телефонын түләүсез урнаштыруга, торак урыннарын ведомстводан тыш саклау сигнализациясе белән түләүсез җиһазлауга һәм аннан файдалануга бәйле чыгымнарны каплый;

«Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасының бүлмә арендалауга һәм телефоннан файдалануга бәйле чыгымнарын компенсацияләү өчен акча түләүне башкара;

оешмаларга шифаханә-курорт юлламалары сатып алуга бәйле чыгымнарны каплый;

Россия Федерациясе Президенты Эшләр идарәсенең «Владивосток шәһәре, Казан шәһәре, Мәскәү шәһәре, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург шәһәре, Симферополь шәһәре һәм Сочи шәһәре аэропортлары (аэродромнары) чикләрендә урнаштырылган Россия Федерациясенең дәүләт чиге аша үткәрү пунктларында оештырыла торган рәсми затлар һәм делегацияләр өчен заллар турында» 2017 елның 31 мартындагы 124 номерлы боерыгы белән расланган Владивосток шәһәре, Казан шәһәре, Мәскәү шәһәре, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург шәһәре, Симферополь шәһәре һәм Сочи шәһәре аэропортлары (аэродромнары) чикләрендә урнаштырылган Россия Федерациясенең дәүләт чиге аша үткәрү пунктларында оештырыла торган рәсми затлар һәм делегацияләр өчен залларга карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1996 елның 19 сентябрендәге 1116 номерлы карары белән расланган Рәсми затлар һәм делегацияләр өчен заллар турындагы нигезләмәне куллану буенча тәгълимнамә нигезендә аэропорт һәм аэровокзалларның, тимер юл вокзалларының һәм станцияләренең, диңгез вокзалларының (портларның) һәм елга вокзалларының рәсми затлары һәм делегацияләр өчен залларда хезмәт күрсәтүче оешманың чыгымнарын каплый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин